ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

КАРАР РЕШЕНИЕ

2019 нчы елның 25 нче марты № 9

Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
бәясен раслау буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 06 нчы октябрендә кабул ителгән 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 нчы елның 12 нче гыйнварында кабул ителгән 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 нче елның 18 нче маенда кабул ителгән 196 нчы номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуганавыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы тәкъдимен кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитетына:
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлгә ашырылуы 2019 нчы елның 30 нчы гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип санарга;
- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 15 нче декабрендә кабул ителгән 29 нчы номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең 2019 нчы елга һәм 2020-2021 еллар план чорына бюджеты турында“ карарына үзгәрешләр кертү турында” карары проектын эшләргә һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Советына тапшырырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча:

http://pravo.tatarstan.ru һәм җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов